ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ТАТАР ӘХТИЯЛЫ АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 24 ноябреннән № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлегенең
Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган үзара салым акчаларын Татар Әхтиялы авылында зиратны төзекләндерү буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендына түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татар Әхтиялы авылы, Үзәк ур., 13А, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru "Турай авыл җирлеге" бүлегендә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Турай авыл җирлеге башлыгы А.М.Рахимова